**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
от 07.09.2020

**КАРАР**
№ 1249

Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының "Питрәч муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын үзгәртү турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүне җайга салу максатларында һәм «бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. «Питрәч муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары үзгәрү турында» Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 14 апрелендәге 576 номерлы карарына, 1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре аерым бюджет даирәсе оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазыйфаи оклады күләменә күчерелә, аларга Питрәч муниципаль районы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый, ул 11 498 сум тәшкил итә;».

2. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Район башкарма
комитеты җитәкчесе — А. В. Хәбибуллин